| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.10.2021 Баулы шәһәре № 39

Физик затлар мөлкәтенә
салым турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибенең бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә мәҗбүри түләү өчен салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Түбәндәге күләмдә салым ставкаларын билгеләргә:

1) 0,1 процент:

гаражга һәм машина урыннарына;

һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык биналарына яисә корылмаларына;

мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм исемлеккә кертелгән салым салу объектында урнашкан, Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән гараж яисә машина урыны;

; Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган урын; Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясы 10 пункты икенче абзацында каралган салым салу объекты;

2) 0,2  процент:

фатирлар, фатирлар өлешләре;

бүлмәләр;

3) 0,3 процент:

торак йортлар, торак йорт өлешләре;

төгәлләнмәгән төзелеш объектлары - мондый объектларның проектланган билгеләнеше торак йорт булса;

составына бер генә торак йорт керсә дә - бердәм күчемсез комплекслар;

4) 2 процент:

Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектлары;

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектлары;

5) Салым салуның башка объектларына карата - 0,5 процент.

3. Ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йортта фатир милекчеләренә ташламалар бирергә, бу фатирның гомуми мәйданындагы утыз квадрат метр салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә.

Әгәр фатир өлешле милектә булса, ташламалар суммасы әлеге фатирга милек хокукы булган һәр кешегә аның өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләп чыгарыла.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектә катнашучы һәр кешегә тигез өлешләрдә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы исәпләп чыгарылган салым суммасыннан артып китә алмый.

4. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән түбәндәгеләрне азат итәргә:

4.1. 18 яшькә кадәрге яки 23 яшькә кадәрге көндезге уку формасында укучы дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга;

4.2. Әлеге пунктның 4.1 бүлегендә күрсәтелгән гражданнарның балалары.

Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1) фатир, фатирның бер өлеше яисә бүлмә;

2) торак йорт яисә торак йортның бер өлеше.

Салым ташламасы гаиләнең салым салынучы бер объектына карата (салым түләүчене сайлау буенча) бирелә.

Салым ташламасы Баулы шәһәре территориясендә даими яшәүче (билгеләнгән тәртиптә яшәү урыны буенча теркәлгән) салым түләүчеләргә алар тарафыннан милекләрендә булган милкендәге һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым ташламасына хокукы булган зат салым органына салым ташламасы алу турында гариза бирә, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.

Кайсы объектка салым ташламасы алуын сайлау турында хәбәрнамәне салым түләүче салым органына күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган салым чоры булган елның 1 ноябренә кадәр тапшырыла».

5. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Баулы шәһәр Советының 2014 елның 11 декабрендәге 113 номерлы карарын (2015 елның 3 июнендәге 134 номерлы, 2015 елның 19 октябрендәге 17 номерлы, 2018 номерлы 20 апрелендәге 74 номерлы, 2018 елның 16 ноябрендәге 93 номерлы, 2019 елның 12 декабрьдәде 122 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга

6. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма ул Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында

(http://pravo.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк түгел.

Әлеге карарның гамәлдә булуы физик затлар мөлкәтенә салымны исәпләү тәртибенә 2021 елдан башлап салым чорларына карата кулланыла.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Баулы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Баулы шәһәре Мэры урынбасары,
шәһәр Советы Рәисе урынбасары К.Ф. Корбанов